| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 08.12.2016 Казан ш. № 3-5/э

«2015-2017 елларга Татарстан Республикасы территориясендә «Электр челтәрләре компаниясе» ЯАҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәрле оешмаларына үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 2014 елның 10 декабрендагы 3-10/э санлы карары белән билгеләнгән Татарстан Республикасы территориясендә территориясендә «Электр челтәрләре компаниясе» ЯАҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәрле оешмаларына үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә озак сроклы индивидуаль тарифларны 2017 елга үзгәртү турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 март № 35-ФЗ Федераль законына, «Электр энергетикасында көйләүле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәяләр кую турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 29 декабрь № 1178 карарына, «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә көйләүле тарифлар һәм бәяләрне исәпләү буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2004 елның 6 август № 20-э/2 һәм «Кирәкле тулаем табышны озак вакытка индексацияләү ысулын кулланып билгеләнә торган электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифларны исәпләү буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2012 елның 17 февраль № 98-э боерыкларына, Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 15.06.2010 № 468 карары белән раслаган нигезләмәгә туры китереп, 2017 елга «Электр челтәрләре компаниясе» ЯАҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәрле оешмаларына үзара

исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә озак сроклы индивидуаль тарифларны һәм 2017 елга җайга салынулы оешманың кирәкле тулаем керемен үзгәртү максатыннан Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы территориясендә «Электр челтәрләре компаниясе» ЯАҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәрле оешмаларына үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 2014 елның 10 декабрендагы 3-10/э санлы карарына (Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 2015 елның 8 июнендәге 3-7/э, 2015 елның 10 декабрендәге 3-11/э санлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 кушымтаны әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итергә;

3 кушымтаны әлеге карарның 2 кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итергә.

2. Шушы карар рәсми басылгач, ун көннән соң, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитетының
08.12.2016 № 3-5/э карарына
1 кушымта.
Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитетының
10.12.2014 № 3-10/э карарына
1 кушымта.

«Электр челтәрләре компаниясе» ЯАҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе тармак оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә, 2015 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 декабренә кадәр, календарга бүлеп индивидуаль тарифлар

| № т/б | Тармак оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | электр челтәрләрен тотуга ставка | технологик чыгымнарны (югалтуларны) түләүгә ставка | | электр челтәрләрен тотуга ставка | технологик чыгымнарны (югалтуларны) түләүгә ставка | |
| | | | сум./кВт·айга | сум./кВт·с | сум./кВт·с | сум./кВт·айга | сум./кВт·с | сум./кВт·с |
| 1 | «Электр челтәрләре компаниясе» ЯАҖ-«Сетевая компания» ААҖ | 2015 | 224 615,56 | 54,83 | 0,74485 | 224 615,56 | 51,65 | 0,74167 |
| | | 2016 | 236 476,78 | 50,77 | 0,81160 | 236 476,78 | 49,54 | 0,81036 |
| | | 2017 | 148 337,47 | 44,92 | 0,97200 | 148 337,47 | 48,06 | 0,97514 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына
2 нче кушымта
08.12.2016 № 3-5/э
Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына
3 нче кушымта
10.12.2014 № 3-10/э

«Электр челтәрләре компаниясе» ЯАҖенең 2015 – 2017 елларга кирәкле тулаем кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| № т/б | Татарстан Республикасындагы тармак оешмасының исеме | Ел | Тармак оешмасының югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча кирәкле тулаем кереме |
|---|---|---|---|
| | | | мең. руб. |
| 1. | «Электр челтәрләре компаниясе» ЯАҖ | 2015 | 12 937,86 |
| | | 2016 | 13 337,29 |
| | | 2017 | 13 581,78» |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге